МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛАГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “04” 08.2015 № 291

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлеген раслау турында

“Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында” 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсенең 3 бүлекчәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы түбәндәге боерыклары үз көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган һәм конкурстан башка гына билгеләнергә мөмкин булган аерым вазыйфалары исемлеген раслау турында” 2013 елның 1 февралендә 13 номерлы;

“2013 елның 1 февралендә 13 номерлы Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү турында” 2014 елның 3 февралендә 33 номерлы.

3. Әлеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2015 елның 04 августында 291
номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вазыйфаи бурычларны башкару, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, конкурстан башка гына билгеләнеп куела торган аерым вазыйфалары исемлеге

финанс бүлеге башлыгы;

транспорт идарәсе башлыгы;

режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге төп белгече.

стратегик үстерү идарәсе башлыгы;

автомобиль юллар бүлеге башлыгы;

тармак аудиты һәм тариф сәясәте бүлеге башлыгы;

режим, мобилизацион әзерлек, гражданлык оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлеге әйдәп баручы белгече.